Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

«15» ноябрь 2023 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2023 елның 15 ноябрендә узган: Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту, грейдер белән тигезләү һәм киләчәктә юл төзү өчен тыгыз нигез салу;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юл өслеге профилен үзгәртеп, вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү мәсьәләсе белән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 147 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 78 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 74 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 4 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту, грейдер белән тигезләү һәм киләчәктә юл төзү өчен тыгыз нигез салу;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юл өслеге профилен үзгәртеп, вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов